**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

07 ноябрь, 2025 ел Мәләкәс авылы № 21

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Җирекле авыл җирлеге Мәләкәс авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2025 елның 21 ноябренә 11:00 сәгатьтә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылында Ветераннар,Көнчыгыш, Дуслык, Җирекле,Көнбатыш, Йолдыз, Я.П.Катков ,Чишмә, Божра урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Иске Җирекле авылы, Дуслык ур., 25А.й. (авыл клубы бинасы); янында билгеләргә.

2. 2025 елның 21 ноябренә 13:00 сәгатьтә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылында Зәңгәрсу, Урман, Болын, Яшьлек, Магистраль, Тынычлык, Өмет, Халык, Парк, Басу, Бакча, Парк тыкрыгы, Дуслык тыкрыгы. урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Иске Җирекле авылы, Дуслык ур., 25А.й. (авыл клубы бинасы); янында билгеләргә.

3. 2025 елныңч21 ноябренә 15:00 сәгатьтә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылында Бердәмлек, Кояшлы, Наратлык, Чәчәк, Узяк, Чаллы, И.Ш.Шакуров, Энтузиастлар, Гәрәбә урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Иске Җирекле авылы, Дуслык ур., 25А.й. (авыл клубы бинасы); янында билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, һәм РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереләчәк, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-торак пункт территориясен төзекләндерү

-урамнарны яктырту җайланмасы (яктырткычлар һәм электр җиһазлары сатып алу, монтажлау);

- тротуарларны төзү, ремонтлау;

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Иске Җирекле авылы, Дуслык ур., 25А.й. (авыл клубы бинасы).

6. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

9. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Р.В.Иванов